# ЗАКОН
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

## О внесении изменений в Закон Республики Татарстан «О ветеринарном деле в Республике Татарстан»

Принят
Государственным Советом
Республики Татарстан
13 июля 2023 года

**Статья 1**

Внести в Закон Республики Татарстан от 13 июля 1993 года № 1934-XII «О ветеринарном деле в Республике Татарстан» (в редакции Закона Республики Татарстан от 19 июля 2005 года № 89-ЗРТ) (Ведомости Верховного Совета Татарстана, 1993, № 6 – 7; Ведомости Государственного Совета Татарстана, 2005, № 7 – 8; 2006, № 11 (I часть); 2007, № 4; 2008, № 1; 2011, № 11 (I часть); 2016, № 7 – 8; Собрание законодательства Республики Татарстан, 2019, № 49 (часть I); 2020, № 26 (часть I); 2021, № 93 (часть I); 2023, № 20 (часть I) следующие изменения:

1) статью 6 дополнить пунктами 14 и 15 следующего содержания:

«14) осуществление учета животных в случаях, установленных в соответствии с законодательством Российской Федерации;

15) определение зоосанитарного статуса объектов – земельных участков, зданий, помещений, строений, сооружений, с использованием которых физические и юридические лица осуществляют деятельность по выращиванию, содержанию и убою животных, по производству, переработке и хранению товаров, подлежащих ветеринарному контролю (надзору), – при отнесении объектов к незащищенным объектам или объектам низкого уровня зоосанитарной защиты, за исключением случаев, указанных в подпункте 3 пункта 2 статьи $19^{2}$ Закона Российской Федерации от 14 мая 1993 года № 4979-I «О ветеринарии» (далее – Закон Российской Федерации «О ветеринарии»).»;

2) в статье 16:

а) наименование изложить в следующей редакции:

«Статья 16. **Производство, переработка, перемещение, хранение и реализация продукции животного происхождения**»;

б) в части 2 слова «заготовку, переработку, хранение, перевозку» заменить словами «производство, переработку, перемещение, хранение»;

3) в части 1 статьи 18:

а) в абзаце третьем слова «животных для осмотра» заменить словами «доступ к животным для осмотра и учета (за исключением доступа в жилые помещения, расположенные в пределах приусадебных земельных участков)»;

б) дополнить абзацами следующего содержания:

«– обеспечить маркирование животных, за исключением случаев, указанных в пункте 3 статьи $19^1$ Закона Российской Федерации «О ветеринарии»;

– представлять сведения, необходимые для учета животных, лицам, осуществляющим учет животных, по перечню и в сроки, которые установлены ветеринарными правилами маркирования и учета животных, за исключением случаев, указанных в пункте 3 статьи $19^1$ Закона Российской Федерации «О ветеринарии».»;

4) в статье 19:

а) в части 1 слова «от 14 мая 1993 года № 4979-I» исключить;

б) в части 2 слова «от 14 мая 1993 года № 4979-I» исключить.

**Статья 2**

Настоящий Закон вступает в силу с 1 сентября 2023 года.

Глава (Раис)
Республики Татарстан — Р.Н. Минниханов

Казань, Кремль
21 июля 2023 года
№ 64-ЗРТ

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
**ЗАКОНЫ**

# «Татарстан Республикасында ветеринария эше турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2023 елның 13 июлендә
кабул ителде

**1 статья**

«Татарстан Республикасында ветеринария эше турында» 1993 елның 13 июлендәге 1934-XII номерлы Татарстан Республикасы Законына (2005 елның 19 июлендәге 89-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы редакциясендә) (Татарстан Югары Советы Җыелма басмасы, 1993, № 6 – 7; Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2005, № 7 – 8; 2006, № 11 (I өлеш); 2007, № 4; 2008, № 1; 2011, № 11 (I өлеш); 2016, № 7 – 8; Татарстан Республикасы законнар җыелмасы, 2019, № 49 (I өлеш); 2020, № 26 (I өлеш); 2021, № 93 (I өлеш); 2023, № 20 (I өлеш) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 6 статьяга түбәндәге эчтәлекле 14 һәм 15 пунктлар өстәргә:

«14) Россия Федерациясе законнары нигезендә билгеләнгән очракларда терлекләрне исәпкә алуны гамәлгә ашыру;

15) физик һәм юридик затлар җир кишәрлекләреннән, биналардан, урыннардан, төзелмәләрдән, корылмалардан файдаланып терлекләр үстерү, асрау һәм чалу, ветеринария контроле (күзәтчелеге) үткәрелергә тиешле товарлар җитештерү, эшкәртү һәм саклау эшчәнлеген гамәлгә ашырганда файдаланыла торган объектларның – җир кишәрлекләренең, биналарның, урыннарның, төзелмәләрнең, корылмаларның зоосанитария статусын билгеләү – объектларны сакланылмаган объектларга яисә зоосанитария яклавы түбән дәрәҗәдә булган объектларга керткәндә, «Ветеринария турында» 1993 елның 14 маендагы 4979-I номерлы Россия Федерациясе Законының $19^2$ статьясындагы 2 пунктының 3 пунктчасында (алга таба – «Ветеринария турында» Россия Федерациясе Законы) күрсәтелгән очраклардан тыш.»;

2) 16 статьяда:

а) исемен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«16 статья. **Терлек продукциясен җитештерү, эшкәртү, күчерү, саклау һәм сату**»;

б) 2 өлештә «әзерләү, эшкәртү, саклау, ташу» сүзләрен «җитештерү, эшкәртү, ташу, саклау» сүзләренә алмаштырырга;

3) 18 статьяның 1 өлешендә:

а) өченче абзацта «хайваннарны тикшерү өчен китерергә» сүзләрен «тикшерү һәм исәпкә алу өчен хайваннар янына керә алу мөмкинлеген (йорт яны җир кишәрлекләре чикләрендә урнашкан торак урыннарга керә алу мөмкинлегеннән тыш) бирергә» сүзләренә алмаштырырга;

б) түбәндәге эчтәлекле абзацлар өстәргә:

«– «Ветеринария турында» Россия Федерациясе Законының $19^1$ статьясындагы 3 пунктында күрсәтелгән очраклардан тыш, терлекләрне маркировкалауны тәэмин итәргә;

– «Ветеринария турында» Россия Федерациясе Законының $19^1$ статьясындагы 3 пунктында күрсәтелгән очраклардан тыш, терлекләрне исәпкә алуны гамәлгә ашыручы затларга терлекләрне маркировкалауның һәм исәпкә алуның ветеринария кагыйдәләрендә билгеләнгән исемлек буенча һәм срокларда терлекләрне исәпкә алу өчен кирәкле белешмәләр тапшырырга.»;

4) 19 статьяда:

а) 1 өлештә «1993 елның 14 маендагы 4979-I номерлы» сүзләрен төшереп калдырырга;

б) 2 өлештә «1993 елның 14 маендагы 4979-I номерлы» сүзләрен төшереп калдырырга.

**2 статья**

Әлеге Закон 2023 елның 1 сентябреннән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Рәисе Р.Н. Миңнеханов

Казан, Кремль
2023 ел, 21 июль
№ 64-ТРЗ